ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 23.07.2025 1193 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы
территориясендә реклама
конструкцияләрен урнаштыру
һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр
төзү хокукына электрон аукцион
үткәрүне гамәлдән чыгару турында

«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон, «Реклама турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 7 маендагы 98-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру турында» 2013 елның 30 октябрендәге 365 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Техник хата белән бәйле рәвештә, 2025 елның 19 июленә билгеләнгән, Алабуга муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына 24000030100000000004 номерлы аукционны гамәлдән чыгарырга.
2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына электрон аукцион үткәрү турында» 2025 елның 3 июлендәге 1105 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында (https://городелабуга.рф), «Новая Кама» газетасында һәм «Интернет» челтәрендә сатуларны үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында (http://sale.zakazrf.ru/) аукцион үткәрүне гамәлдән чыгару хакындагы хәбәрне бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Лист согласования к документу № 1193 от 23.07.2025
Инициатор согласования: Каретина К.Д. Главный специалист
Согласование инициировано: 04.08.2025 16:56

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 04.08.2025 - 20:53 | - |